| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

2019 елның «27» июне №829

2019 елга Лениногорск муниципаль районы территориясендә үзләштерелмәгән юл фонды калдыклары хисабына юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча финанслау һәм объектларны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында» 2018 елның 17 декабрьендәге 1149 нчы карарын үтәү йөзеннән, Лениногорск муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга Лениногорск муниципаль районы территориясендә үзләштерелмәгән юл фонды калдыклары хисабына юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча финанслау һәм объектларның тәкъдим ителгән исемлеген расларга.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге МКУ «Финанс-бюджет палатасы» рәисе Р. Х. Хәмидуллинга чыгымнарның тиешле статьясы буенча әлеге эшләрне финанслауны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы З.Г. Михайлова

М.Г. Якупов
5-15-41

Расланды

“Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән

2019 елның 27 июне № 829

2019 елга Лениногорск муниципаль районы территориясендә үзләштерелмәгән юл фонды акчасы хисабына финанслана торган юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү эшләре исемлеге

| № п/п | Объектның атамасы | Егәрлеге км,пог.м,кв.м | Гамәлдәге бәядән капиталь салымнар, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **Муниципаль юл фонды средстволары хисабына башкарылучы чаралар** | | | |
| 1 | Шашин-Кутузов урамында җәяүлеләр өчен әйләндереп алу | 80 м. | 224080 |
| 2 | ИДН Моряков-Ленин урамы | 6 данә. | 438472 |
| 3 | ИДН Сельхозтехника-Бугульминская | 6 данә. | 330706 |
| 4 | Чайковский урамында Лукойл заправкасы янында, Шашин-Моряков, Ленин-Моряков, Шашин-Куйбышев урамнарында ) 5.19.1 (2) юл билгеләре | 14 данә | 748266 |
| 5 | Яңа чыршылы поселогында һәм Иске Куакта тукталыш павильоны | 2 данә | 596906 |
| 6 | Бүленмәгән лимит | | 0,020 |
| **2019 елның 1 гыйнварына МДФ калдыгы буенча барлыгы** | | | **2 338,45** |